СӨЙ ГӨМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ
ОБЩЕСТВЕННО - ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №131 (7304) | 2 ноябрь, 1991 ел. ШИМБӘ | Бәясе 4 тиен

## Ишеттегезме әле...

*Теләсә кайсы көнне Россия үз акчасын чыгара башларга мөмкин, дип белдерде ТАСС хәбәрчесенә Россия Үзәк банкының информация идарәсе башлыгы Михаил Беляев.

*Россия прокуратурасы белдерү таратты. Татарстандагы, Чечен-Ингуш республикасындагы, Саратов өлкәсендәге һәм башка төбәкләрдәге сәяси хәлгә бәйле рәвештә, төрле берләшмәләрнең, кешеләрнең, шулай ук массакүләм информация чараларының милли низаг чыгаруга, массакүләм тәртипсезлекләргә котыртуга һәм РСФСР чикләренең бөтенлеген бозуга өнди торган эшчәнлеге җинаять җаваплылыгына тарту рәвешендә туктатылачак, дип кисәтелә.

*СССР Президенты М. Горбачев СССР Югары Советы каравына хәрби хезмәттән качып йөрүче хәрби хезмәткәрләргә амнистия турында карар проектын кертте. Шунысы сәер: проект Оборона министрлыгы кабинетларында туган.

*АКШ Президенты Бушны саклаган 40 ка якын диңгез пехотачысы наркотиклар куллануда гаепләнеп суд каршына басты. Хәрби трибунал 14 сакчыга хөкем карары чыгарды. Бу кешеләр Бушны саклаудан буш вакытта башкаланың төнге клубларында марихуана тартып ятканнар.

*Әрмәнстан халкының өчтән бере СССР белән бернинди элемтәне калдырмау таләбен куя.

*Иркутск шәһәрендә Колчакка һәйкәл куярга йөриләр.

*Кырымда референдум үткәрелмәячәк. Украина Югары Советы Рәисе фикеренчә, Кырым үз мәсьәләләрен үзе хәл итәргә тиеш. Әмма, Украинаның состав өлеше буларак, Украина законнарына буйсынырга тиеш.



Александрга игеннәр шавы, тук башаклар җыры күптәннән таныш. Армиягә киткәнче үк ул колхозда комбайнда эшләгән иде, маңгай тире түгеп үстергән икмәкнең тәмен белергә өлгерде. Хәрби хезмәттән кайткач, 3 ел шофер булып эшләде, ә инде быел җәй «Колос» комбайнына утырды, янә ашлык өчен көрәшүчеләр сафына кушылды. Элеккеге күнекмәләрен онытмаган икән, егет сынатмады. Аннан соң БМ-6 чөгендер яфрагын урдыру комбайнында да шундый ук теләк, дәрт белән эшләде. Яшьлек энергиясе, аңа хас эш сөючәнлек Александр Александровичны колхозның өметле, ышанычлы яшьләреннән берсе дип санарга мөмкинлек бирә.

Рәсемдә: Синдряков исемендәге колхоз механизаторы А. А. Шаронов.

## Аңлашу шартларында

Якушкино авылында сугыш һәм хезмәт ветераннарының отчет-сайлау җыелышы мәктәпнең актлар залында үтте. 90 лап ветеран алдында башлангыч оешма Советы эше турында отчетны аның рәисе Матвей Максимович Алякимов ясады. Ул ветераннарның тормыш һәм көнкүрешен җиңеләйтүдә Совет башкарган эшләргә тукталды, алар ихтыяҗын канәгатьләндерүдә колхоз җитәкчелегенең ярдәмен ассызыклады, өлкәннәр еш юлыга торган проблемаларны да читләтеп үтмәде. Фикер алышуда катнашучылар Якушкинсда бер генә сатучы булганлыктан, кибетнең еш кына бикле булуына ризасызлык белдерделәр, гомумән, сәүдә эшенә тәртип салу кирәклегенә басым ясадылар. Бик күп ветераннар авылга үзвакытында ипи кайтару, пешкән камыр ризыклары китереп сатуга шатлануларын белдерделәр. Гомумән, колхоз идарәсе аларның транспорт, утын, терлек азыгына булган сорауларын бер дә кире какмый икән, авылдагы үзгәрешләр дә аларны чын күңелдән сөендерерлек. Аннан колхоз рәисе Ф. Х. Хөсәенов хуҗалыкның бүгенге экономик хәле, киләчәккә планнары белән таныштырды. Җаваплы кампанияләр вакытында, фермаларга ремонт, ындыр табагында эшләү һәм башкаларда колхоз идарәсенең ветераннарга ярдәменә еш мөрәҗәгать итүен, алардан һәрвакыт булышлык һәм ярдәм күрүләрен, колхоз рәисе шулай ук шатланып сөйләде.

—Сез, өлкәннәр, безгә һәрчак киңәшче дә, булышчы да,—диде ул.

Җыелышта катнашучылар оешманың 9 кешедән торган яңа Советын сайладылар. Шәхси үтенече буенча аның элеккеге рәисе М. М. Алякимов рәис урынбасары итеп сайланды, ә Совет рәисе итеп Ермак Тимофеевич Ермилов күрсәтелде.

Бу көнне өлкәннәр өчен буфет эшләде, җыелыш ахырында алар өчен аш-чәй табыны әзерләнгән иде.

Колхоз белгечләре, барлык төр службалар авыл һәм колхоз җитәкчеләре катнашындагы бу чара үзара аңлашу шартларында, ачыктан-ачык сөйләшү рәвешендә үтте.

**Н. ЛАРИОНОВ,**
сугыш һәм хезмәт ветераны.

## Тәэминатчылар уңышы

«Агропромснаб» базасы коллективы франкохуҗалык шартларында 9 айлык планны 113,62 процент итеп, ягъни 659 мең сумга арттырып үтәде. Система эчендәге товар әйләнеше 6 миллион сум урынына 11 миллион 202 мең сумга башкарылды, ә транзит төяве 620 мең сум итеп гамәлгә ашырылды.

Коллективның бу уңышына аның хезмәт алдынгыларының өлеше күп керде. Моннан тыш аңа базада тудырылган хезмәт һәм ял шартларының да уңай йогынты ясавын билгеләргә кирәк. Эшчеләр өчен бирегә сауна эшли, кайтарылган техника бушатыла торган мәйданчык, тимер юл переездыннан складларга илтә торган юл асфальтланды. Хәзерге вакытта коллективта торак проблемасы да хәл ителү юнәлешендә: 2 фатирлы йорт төзелә, 27 фатирлы торак йортның проекты әзер. Җыю цехында эшчеләр карамагында бик әйбәт җиһазланган көнкүреш бүлмәсе бар.

Мондый шартларда коллективның бердәм омтылышы белән еллык планны да уңышлы үтисебезгә ышаныч зур.

**М. ВЕДЕНИНА,**
баш бухгалтер.

*Аларның визит карточкасы*

## Норлат сәүдә йорты ул нәрсә?

**Бу яңа фирманың бурычлары, максаты турында укучыларга берничә сүз әйтүне үтенеп, без «Сәүдә йорты»ның президенты вазифаларын башкаручы А. С. Хәйруллин һәм аның башкарма директоры Ф. Н. Гобәйдуллинга мөрәҗәгать иттек. Аларның кыска җавапларын сезгә тәкъдим итәбез.**

—Норлат сәүдә йорты базар структурасы, ул заман, ихтыяҗ таләбе нигезендә туган яңа берләшмә. Ул Идел—Кама регионында халыкны, предприятие, оешма, учреждениеләрнең, төрле милек формаларындагы хуҗалыкларның товарлар һәм производство-техник билгеләнештәге авыл хуҗалыгы, халык куллануы продукцияләренә булган ихтыяҗларын канәгатьләндерүне, производство һәм торак-социаль объектлар төзүне гамәлгә ашыруны максат итә.

**—Бу максатларны нинди чаралар белән гамәлгә ашыру күздә тотыла?**

—Берничә юнәлештә. Иң элек предприятиеләргә, аерым кешеләргә җитештерүче табарга булышу; биржа хезмәте күрсәтү— продукцияне реализацияләүдә квалификацияле ярдәм итү; моңа кадәр әйләнештә йөрмәгән төп фондларны, шулай ук нелеквидларны эшкә җигү—болар һәммәсе фирма эшчәнлегендә җитди урын алачаклар.

**—Мондый катлаулы эш башлау нияте кайчан, ничек туды?**

—Ничек бусы, әйткәнебезчә, базар мөнәсәбәтләре чорында котылгысыз. Инде вакытына килгәндә, реаль эшкә әзерлек, брокерлар белән ният беркетмәләрен төзи башлауга 1 еллап вакыт үткәндер.

**—Һәм сез бүген нинди хәлдә?**

—Бүген безнең 11 учредителебез, әйләнеш средствобыз бар. Берничә килешү төзергә өлгердек, аерым алганда Әрмәнстан белән аяк киемнәре, Ульяновск белән көнкүреш товарлары алуга килешү төзелде, бу эш дәвам итә. Ноябрь аенда беренче партия товарлар кайтуны көтәбез. Нигездә без киләчәктә халыкны киң куллану, көнкүреш товарлары белән тәэмин итүне күздә тотабыз. Хаклары килешү бәяләрендә булачак. Бартер алмашуын сорап үз артык продукцияләрен тәкъдим итүче беренче хуҗалыклар да бар инде. Аларга квалификацияле коммерция хезмәте күрсәтү—безнең төп бурыч.

**—Һәм сезнең хезмәттән кем файдалана ала инде?**

—Без килешү нигезендә һәркемгә хезмәт күрсәтергә әзербез. Безнең телефоннар: 2—14—69, 2—29—71.

**Әңгәмәне С. ХӘЙРУЛЛИНА алып барды.**

## Хөрмәтле норлатлылар, райондашлар!

**7 ноябрь көнне шәһәрнең сәүдә үзәгендә көзге ярминкә үткәрелә.**

**Бу көнне район потребительләр җәмгыятенең, эшчеләрне тәэмин итү бүлекләренең һәм җәмәгать туклануы предприятиесенең сәүдә нокталары шәһәр һәм район халкына киң ассортиментта товарлар, колхоз-совхозлар, авыл Советлары авыл хуҗалыгы продукциясе тәкъдим итәчәк.**

**Җыр-бию, нәфис сүзгә сәләтле үзешчәннәрне шул ук мәйданда оештырылачак иң яхшы сәнгать номерына конкурска чакырабыз.**

**Теләүчеләр дефицит товарлар сату буенча сәүдә аукционында катнаша алалар, көзге-кышкы сезон модельләрен күрсәтү дә кызыксыну уятыр дип уйлыйбыз.**

**Районда популярлашкан «Спринт» уены билетлары бу көнгә 10 мең данәдә сатылачак, бәхетлеләргә бензопычкы, кул, өстәл, стена сәгатьләре, электробритвалар һәм акчалата отышлар насыйп булачак. Аның бәясе 1 сум.**

**Ярминкәгә рәхим итегез! Ул сатып алучыларга сәгать 8 дән хезмәт күрсәтә башлаячак.**

**ОЕШТЫРУ КОМИССИЯСЕ.**

## Бүгенге санда

*ДЕПУТАТ БЕЛӘН ӘҢГӘМӘ
*ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ АРТЫНДА
*АЛАРНЫҢ ВИЗИТ КАРТОЧКАСЫ
*КЕШЕ ҺӘМ ЗАКОН